**Татарстан Республикасы**
**Нурлат муниципаль районы**
**Фома авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**19 декабрь 2025 ел** **№ 13**

**Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлегенең 2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына бюджеты турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

**Статья 1**

1. 2026 елга Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга.:

1) Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 3 547,11 мең сум күләмендә;

2) Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 3 547,11 мең сум итеп. сум.

3) Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 0,0 мең сум.

2. 2027 һәм 2028 еллар план чорына Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1)Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 2027 елга 3 780,84 мең сум һәм 2028 елга 4 069,08 мең сум күләмендә;

2)Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2027 елга 3 780,84 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланганнары 88,34 мең сум күләмендә, һәм 2028 елга 4 069,08 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланганнары 187,69 мең сум күләмендә;

3)Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 2027 елга 0,0 мең сум, 2028 елга 0,0 мең сум.

3. Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

**Статья 2**

Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге бюджетында 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына керемнәр күләмен әлеге карарга 2 нче кушымта

нигезендә исәпкә алырга.

**Статья 3**

Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге бюджет ассигнованиеләрен 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

**Статья 4**

Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге чыгымнарының ведомство структурасын 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

**Статья 5**

2026, 2027 һәм 2028 елларга гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелгән бюджет ассигнованиеләре күләмен 0,00 мең сум күләмендә расларга.

**Статья 6**

2026, 2027 һәм 2028 елларга гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелгән бюджет ассигнованиеләре күләмен 0,00 мең сум күләмендә расларга.

**Статья 7**

Территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекчәләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыруга субвенцияләр күләмен 2026 елга 221,45 мең сум күләмендә, 2027 елга 247,23 мең сум күләмендә, 2028 елга 315,26 мең сум күләмендә расларга.

**Статья 8**

1. 2027 елның 1 гыйнварына Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген 0,00 мең сум күләмендә, шул исәптән Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген муниципаль гарантияләр буенча Россия Федерациясе валютасында нульле әһәмиятле итеп расларга..

2. 2028 елның 1 гыйнварына Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген 0,00 мең сум күләмендә, шул исәптән Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген муниципаль гарантияләр буенча Россия Федерациясе валютасында нульле әһәмиятле итеп расларга.

3. 2029 елның 1 гыйнварына Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген 0,00 мең сум күләмендә, шул исәптән Нурлат муниципаль районы муниципаль эчке бурычының югары чиген муниципаль гарантияләр буенча Россия Федерациясе валютасында нульле әһәмиятле итеп расларга.

**Статья 9**

Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге җирле үзидарә органнары 2026 елда һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорында муниципаль хезмәткәрләр һәм бюджет өлкәсе учреждениеләре һәм оешмалары хезмәткәрләре санын, шулай ук

аларны тоту чыгымнарын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел, моңа Татарстан Республикасы законнарында каралган очраклар керми.

**Статья 10**

Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге бюджетының 2026 елның 1 гыйнварына Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге исеменнән төзелгән товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә 2025 елда шушы муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле муниципаль контрактлар өчен түләүгә файдаланылмый калган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган калган акчалары Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта 2026 елда күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга тотыла.

**Статье 11**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Нурлат районы буенча Казначылык Департаментының территориаль бүлеге Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге бюджетын үтәүне, шулай ук Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне төзелгән шартнамәләр нигезендә гамәлгә ашыра.

**Статья 12**

Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Статья 13**

Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Фома авыл җирлеге Советы Р.Х. Абдрахманов